СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

23 апрель, 1997 ел. ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 44 (8056) | Бәясе билгеләнгәнчә

# ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ, ИГЕНЧЕ!

## Районыбыз игенчеләре республикада иң беренче булып язгы кыр эшләренә керештеләр.

**Игененең сынау сәгате сукты, аның вакытны үз үлчәү берәмлеге белән исәпли торган киеренке көннәре башланды.**

**Быелгы язның үзенчәлекләрен һәм алда торган эшләрнең күләме елдагыдан зуррак булуын исәпкә алып, игенчеләребез язгы агрочараларны тулы комплекста үткәрү өчен беренче көннәрдән үк эшкә киң колач белән тотындылар. «Якты Күл»,«Кондырча», Мичурин исемендәге,«Игенче», «Рассвет»,Синдряков исемендәге,«Заря», Киекле хуҗалыклары быел аеруча өлгерлек күрсәтәләр. Кичәге көнгә барлык хуҗалыкларда диярлек агрегатлар кырда иде инде. Барлыгы 2300 гектардан артык мәйданда дым каплату уздырылды, 1850 гектар мәйданда күпьеллык үләннәр тамырдан тукландырылды һәм тырмаланды. Уҗым тукландыру, начар кышлаган участокларда өстәмә чәчү эше дә бара.**

**Мичурин исемендәге, «Кондырча» һәм кайбер башка хуҗалыкларда өлгергән кырларга иртә сабан культуралары чәчүгә дә тотындылар.**

**Ил - көнне ризыклы итү хакына башлаган изге эшегездә түземлек һәм сабырлык сезгә, кадерле авыл хезмәтчәннәре!**

## Күмәк эштән - бердәм шытым

Бормалы юлның әле бер, әле икенче ягында кап - кара булып җәйрәп яткан басулар игезәкләр төсле тип - тигез, әйтерсең, кемдер учлары белән әле генә кара туфракны тигезләп җәеп чыккан. Әнә, сизелер - сизелмәс беленеп торган тырма эзләре дә бармак эзе сыман...

- Көздән шулай әзерләп калдырырга тырышабыз басуларны,- ди бригада агрономы Вәгыйзь Галимов. - Әнә чөгендер чәчеләсе җирне известьладык та, ашламасын да керттек, культивацияләдек тә. Рәхим ит - яздан сызганып торып эшкә тотынырга була.

Шулай иткәннәр дә Югары Норлатта. Хәзер чөгендер чәчеләсе 190 гектарлы басуда татлы тамыр игү «профессоры» атаклы чөгендерче Шамил ага Яруллин райтырмалар белән тырмалау үткәрә. Аннан - шома каток белән узарга җыена. Болай иткәндә, җир тыгызланып, чүп үлән өскә чыгасы икән. Аннан шул чүп үләне дигән зәхмәттән ВНИИССР ярдәмендә котылырга да «Мультикорн» белән чөгендер чәчәргә тотынырга ниятлиләр. Ничек, берүземе? Ә Зәйдулла Мөхәмматов?

- Быел берүзе җиңәргә уйлый. Зәйдулла рәт араларын эшкәртү башлангач ярдәмгә киләчәк, - ди агроном.

Әлбәттә өлгерә икән, нигә дип бер басуда артык кеше тотарга ди? Зәйдуллага да эш бетмәгән бит.

Югары Норлат быел чәчүне «Кондырча» КХАсының бер бригадасы булып каршылый. Хуҗалык үзгәрсә дә эшкә мөнәсәбәт үзгәрмәгән. Элеккечә, дөресрәге, югары норлатлыларча эшнең һәр этабын уйлап, бердәм тотынып, җиренә җиткереп башкаралар. Ул күзгә әзерлектән үк күренә. Җирләре бер дигән әзерләп калдырылган, чәчәсе орлыклары - һәммәсе I классы. Ашлама да җиргә бер гектарга физик авырлыкта 6 центнер исәбеннән тупланган. Аны җиргә кертү өчен төягече, төягечкә биреп тора торган җайланмасы да ясалган, берсен дә кул белән күтәреп - төшереп азапланасы юк. Аларны да, орлык төягечне дә әлеге дә баягы Шамил ага Яруллин ясаган. Төягеч җайланмасын яссы транспортердан көйләгән. Уңышлы нәтиҗә шулай вак күренгән нәрсәләрдән туплана бит.

Бәхеткә, уҗымнары да исән - имин кышлаган, 214 гектарның бер генә гектарына да өстисе - төзәтәсе юк. Хәзерәнә янә эшне комплексны алып баралар. 11 тракторның һәммәсе - басуда, караңгы төнгәчә эшлиләр, бүген - иртәгә төнге сменага чыгарга торалар. 1 нче басуларында кукуруз чәчеләсе мәйданда Солтангәрәй Мөхәмматов дым каплату үткәрә. Ул - кукуруз үстерүдә шулай ук «профессор» дәрәҗәсендәге тәҗрибә - белем туплаган механизатор, елның - елында шул культураны игә. Быел 140 гектарда бөртеккә, 110 гектарда силоска дигән «кыр патшасы» янә аның җаваплылыгына тапшырылган. Дүртенче номерлы кырда Минислам Мусин агрегаты борчак чәчә. Ул үзе бульдозерчы, әмма 5 нче ел инде язны - көзне басуда каршылый. Чәчүчеләре Каюм Фәтхетдинов, Минсалих Төхфәтуллин, Ирек Хисамов белән бергә 85 гектарда силоска, 21 гектарда бөртеккә борчак чәчәчәкләр. Минвәли Алиев ашламасын, Илдус Шәфиев - борчакны китереп кенә торалар. Егетләргә акрын кыймылдарга җай юк, җирләр күзгә күренеп өлгерә. Әле бит 100 гектарда сабан бодаен да чәчәсе бар.

Хәер, югары норлатлылар йоклап ята торган халык түгел. Чәчүне тулысынча апрель азагына тәгәлләргә җыеналар. Моның өчен шартлар бар дип исәплиләр: техника сау - сәламәт, кешеләр җитәрлек, кырдагыларга хезмәт күрсәтү - 2 вакыт ашату оештырылган. Шуңа да бүген юл буйлап кап - кара, тигез булып игенче кулы тигәнне күтәп күпереп торган басуларда тиздән, бик тиздән хәтфә шытымнар күтәреләсенә шик юк. Күмәк башланган эш һәрчак бердәм шытым да бирә бит.

С.ХӘЙРУЛЛИНА.





Рәсемнәрдә: Минислам Мусин агрегаты эштә.

Н.АЗИЗОВ фотолары.

## Өч көндә - 260 гектар

*МСОның «Төзүче» ярдәмче хуҗалыгында өч көн эчендә шул кадәр мәйдандагы күпьеллык үләннәр тамырдан тукландырылды. Бу эшне Ислам Бәхтияров, Виктор Матвеев, Геннадий Мензелеев җитәкчелегендәге өч агрегат башкарды.*

*Хәзер туфрагы кипшенгән мәйданнарда дым каплату эшенә дә керешәләр механизаторлар.*

Ә.МИНСАБИРОВ.

## Хуҗалыклар берләштерелде

Узган шимбә көнне Киекле һәм «Чишмә» крестьян хуҗалыклары ассоциацияләре берләштерелде. Берләшкән Киекле кооперативлар ассоциациясе рәисе итеп Наил Шакир улы Шарапов сайланды.

## Рәсми хроника

### Рәис алышынды

Җир ресурслары һәм җир реформасы буенча Октябрь район комитеты рәисе итеп Әнвәр Гәрәй улы Шәяхмәтов билгеләнде.

***

## ДРСУда - яңа начальник

Район юл ремонтлау - төзү идарәсенең яңа начальнигы итеп моңарчы идарә начальнигы урынбасары булып эшләгән Роберт Адлер улы Газизуллин билгеләнде.

## Сайлаучылар игътибарына!

1997 елның 3 маенда көндезге сәгать 3 тән кичке 6 га кадәр халык депутатларының район Советы бинасында ( 2 нче кат, оештыру бүлеге инструкторы бүлмәсе) Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы депутаты Азат Кыям улы Хамаев сайлаучыларны кабул итәчәк. Белешмәләр өчен тел.: 2 - 11 - 11.

## Район Советы сессиясендә

21 апрельдә халык депутатлары Октябрь район Советының унынчы сессиясе булып узды.

Сессиянең түбәндәге көн тәртибе расланды.

1. Халык депутатларының Октябрь район Советына халык депутатын сайлау йомгаклары турында.
2. Районның аграр промышленностендә реформацияләүнең барышы турында.
3. Промышленность, төзелеш, транспорт һәм элемтә буенча даими комиссия эше турында.
4. Район Советы депутатының сайлау округында, даими комиссиядә эше, Совет поручениеләрен үтәве турында.
5. Даими комиссияләр составын үзгәртү турында.
6. Октябрь районы исемен үзгәртү турында.
7. Район буйсынуындагы Норлат шәһәрен республика буйсынуындагы шәһәр категориясенә күчерү турында.

Көн тәртибе буенча беренче булып район сайлау комиссиясе рәисе **Н.Х.Абдуллин** чыгыш ясады. Аның 18нче Егоркино сайлау округы буенча район Советына халык депутаты сайлау нәтиҗәләре буенча информациясе игътибарга алынды. Шунда ук халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе **А.С.Насолдинга** депутат таныклыгы һәм күкрәк билгесе тапшырылды.

Район агропромышленностендә реформацияләүнең барышы турында доклад белән район хакимияте башлыгы урынбасары район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы **Ә.Н.Рәхмәтуллин** чыкты. Өстәмә докладны аграр мәсьәләләр буенча даими комиссия әгъзасы **Р.Р.Хәмзин** (12 нче Аксумла - Якушкино сайлау округы) ясады. Фикер алышуларда депутатлар **Р.С.Чахмахчев** (8 нче Октябрь), **А.К.Савинов** (1 нче Завод), **А.И.Савинов** (9 нчы Тельман), **Ә.Ә.Гарифуллин** (20 нче Төньяк) сугыш һәм хезмәт ветераннары район Советы рәисе **И.У.Гыйләҗев** катнаштылар.

Промышленность, төзелеш, транспорт һәм элемтә буенча даими комиссия эше турында информацияне комиссия әгъзасы депутат **А.И.Газизуллин** (4 нче Куйбышев) ясады.

Аннан соң депутат **А.И.Савиновның** сайлау округында, даими комиссия эше, Совет поручениеләрен үтәве турында информациясе тыңланды. Депутатлар даими комиссияләрнең эшен яхшырту һәм депутат сайлану уңаеннан законлылык һәм хокук саклау, аграр мәсьәләләр һәм промышленность, төзелеш, транспорт һәм элемтә буенча даими комиссияләрнең составын үзгәртү турында мәсьәлә карадылар.

Аннан соң халык депутатларының район Советы рәисе **Ф.С.Сибагатуллин** Октябрь районын Норлат районы дип үзгәртү һәм район буйсынуындагы Норлат шәһәрен республика буйсынуындагы шәһәр категориясенә кертү мәсьәләләре турында белдерү ясады. Залда утыручыларга аңлатуынча, аның беренчесе район үзәге һәм тимер юлның, байтак эре промышленность, транспорт предприятиеләренең исемнәре Норлат белән бәйле булуын аңлатты, бу җәһәттән хезмәт коллективлары җыелышлары гражданнар җыеннары карарлары булуын да әйтте. Норлатны республика буйсынуындагы шәһәрләр категориясенә кертү мәсьәләсендә исә депутатларга шәһәр хуҗалыгын интенсив үстерү, промышленность, төзелеш һәм транспорт предприятиеләре челтәрен киңәйтү, халык саны арту һәм шәһәрнең киләчәктә экономик һәм социаль - культура үсеше перспективаларын исәпкә алып карау тәкъдим ителде. Совет районны Норлат районы итеп үзгәртү һәм башка категориягә кертү турында тәкъдим белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына чыгу мәсьәләсе белән тулы составта ризалашты.

Район Советы тикшерелгән һәр мәсьәлә буенча тиешле карар кабул итте. Сессия эшендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы әйдәп баручы референты **А.Н.Ельченков** катнашты.

Сессиягә җирле үзидарәләр Советлары рәисләре, район хуҗалыклары, шәһәр предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре, район хакимияте бүлек мөдирләре, идарәләр начальниклары, мәктәпләр директорлары чакырылганнар иде.

Сессияне халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе **Ф.С.Сибагатуллин** алып барды.

***

Сессиядән соң район хакимияте башлыгы **Ф.С.Сибагатуллин** район активын соңгы вакытта көйле эш, производство һәм хезмәт дисциплинасын ныгыту исәбенә терлекчелектәге практик үзгәрешләр белән таныштырды. Терлекчеләр тагын да нәтиҗәлерәк эшләрләр дигән өмет бар, диде ул. Малларны җәйге лагерьларга күчерүне беренче чираттагы бурыч дип атады ул: бу эш никадәр иртәрәк башкарылса, нәтиҗәләре дә шул кадәр үк булачак. Таналар һәм беренче кат бозаулаган сыерларны яхшы карау һәм азык белән тәэмин итеп, фермаларда калдырырга кирәк.

Халыктан сөт сатып алуны анализлап, хакимият башлыгы бу юнәлештә байтак җирле үзидарә Советларының канәгатьләнмәслек эшләвен билгеләде. Сөт сатуның өстәмә акча чыганагы булуына басым ясап ул суган үстерүгә дә зур игътибар бирергә кирәклеген әйтте.

Шулай да Ф.С.Сибагатуллин үз чыгышында төп игътибарны язгы кыр эшләренә юнәлтте, аларның быелгы үзенчәлекләрен билгеләде. Югары Норлат авылы, Киекле, Мичурин исемендәге һәм «Үрнәк» ассоциацияләренең бу эшкә актив керешүен билгеләп, Фатих Сәүбәнович тагын бер кат искәртте: соңгы яңгырдан соң җир барлык мәйданнарда да тигез өлгерәчәк, шуңа да язгы көннең һәр сәгатен нәтиҗәле файдаланырга, ике сменалы эш оештырып, һәр җирдә дымны сакларга, барлык культураларны иртә срокларда, яхшы сыйфат белән, минераль ашламалар кертеп чәчәргә кирәк. «Игенчеләр үз алларына җитди һәм җаваплы бурыч куйдылар. Җирне алдап булмый. Һәр гектардан 40 центнер уңыш җыю җиңел булмаячак,» - дип тәмамлады ул үз чыгышын.

Ахырдан. Ф.С.Сибагатуллин «Кондырча» КХАсы рәисе **Й.Г.Әхмәтсафинга** «Татарстан Республикасы атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исеме бирелү турында Мактау кәгазе һәм күкрәк билгесе тапшырды.

Т.НАЗАРОВА.

## Мәдәният

### Безнең интервью

# КАБЫНЫП АЛУ ГЫНА БУЛМАС

***Соңгы вакытта районда барган социаль - икътисадый үзгәрешләр белән бергә мәдәни күтәрелеш тә халык күзеннән читтә калмады. Райондашларның рухын күтәрердәй тамашалар, сәнгать бәйгеләре, ял концертлары тамашачыларның күңеленә хуш килерлек югары әзерлек дәрәҗәсендә узулары белән дә игътибарны җәлеп иттеләр.***

***Бу чараларны район мәдәният тормышындагы рухи күтәренкелек, җанлануга йөз тоту дип аңларгамы яки вакытлыча кабыну дип кенә бәяләргәме? Шул сорау белән без район хакимияте башлыгының социаль - мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Р.НОГЪМАНОВАГА мөрәҗәгать иттек.***

Заманның болгавыр җилләре икътисадка гына түгел, мәдәни дөньяга да кагылмый калмады. Матди гына түгел, рухи кыйммәтләр дә үзгәрде, халыкның зәвыгы - ихтыяҗы да үсте, аларны канәгатьләндерү чыганаклары да артты. Элек йөгерә - йөгерә клубка кино карарга йөргән халыкны бүген юк кына сәбәп белән өеннән чыгарам димә, аңа җәлеп итәрлек үзенчәлекле чара кирәк. Үзешчән сәнгатькә халыкны тартуда да шундый четреклелекләр бар: коры энтузиазм чоры артта калып бара, бары алар күңеленә юл таба алган фидакарьләр генә талантларны туплый, үз артларыннан ияртергә мөмкиннәр. Андыйларга исә һәр җирдә кытлык. Шуңа мәдәниятны калдык принцибы буенча финанслауны да өстәсәк...

Районда мәдәният тормышындагы чагыштырмача торгынлык сәбәпләрен шуннан эзләргә кирәктер димәкче булам. Инде соңгы вакыттагы җанлылыкка килсәк, анысы тормышыбызның һәр тармагында башланган икән, ни дип культурага кагылмаска тиеш ди? Аннан мәдәният өлкәсендә кадрлар үзгәрешләре дә булды бит әле. Шуңа культура тормышындагы бу хәрәкәтне вакытлы гына дип түгел, халыкка заманча зәвыклы культура хезмәте күрсәтүгә зур теләк белән йөз алу дип бәялисе килә.

**- Дөрестән дә, мәдәни аралашулар соңгы вакытта күп булды шул...**

- Әйе, әле узган айда гына да концерт бригадалары 60лап төбәктә чыгыш ясадылар. Алар арасында район культура йорты каршындагы рус концерт группасы, «Родник» ансамбле катнашында чуваш бригадасы һәм күптармаклы җитештерү предприятиесе татар концерт коллективы бар иде. Соңгыларын аерып әйтәсебез килә, чөнки алар үз транспортлары белән районның иң ерак төбәкләренә барудан да баш тартмадылар. Бикүле һәм Норлат халык театрлары да спектакльләр белән халык алдында чыгышлар ясадылар. Сүз уңаеннан, алар Чистайда халык театрлары зона ярышларында да уңышлы чыгыш ясап кайттылар. Шул арада Масленица, Науруз кебек массовый күңел ачулар үтте, авыл мәдәният йортларында бәйрәм программалары узды. Үзешчәннәребез республика бәйгеләрендә уңышлы чыгышлары белән дә безне сөендерделәр. Балалар музыка мәктәбе каршында хатын - кызлар ансамбле (җитәкчесе - Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Т.Бадыйгин) «Татарстан - минем республикам» дигән республика конкурсында лауреат исемен яулап кайтты. «Чуваш сандугачы - 97» республика смотр - конкурсында «Родник» җыр ансамбле (җитәкчесе - Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре С.Ефремова) һәм солистка И.Сафандеева лауреат, ә Урта Камышлыдан «Росинка» балалар ансамбле (җитәкчесе Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Н.Бочкарев) дипломант исеменә лаек булдылар. Район данын уңышлы яклаучы талант ияләрен чын күңелдән котлыйбыз, киләчәктә безнең үзешчәннәр тавышы республикада ышанычлырак яңгырарга тиеш, дип ышанабыз.

**- Бу җәһәттән безнең даими авторыбыз Мөхәммәтгалимнең газетадагы мәкаләсе күпләрнең күңеленә тигәндер. Ул мәдәниятның матди тәэмин ителеше, материаль база хакында иде...**

- Сүз дә юк, автор хаклы! Үзешчәннәребезнең затлы концерт костюмнары, культура йортларыбызның җитәрлек уен кораллары бар дип мактана алмыйбыз. Культура учакларының байтагына зур - зур ремонт кирәк, аларның бизәлеше дә 60 - 70 еллар дәрәҗәсендә. Алдан әйткән финанслауның калдык принцибының нәтиҗәләре болар һәм аларны бер селтәнүдә хәл итәргә вәгъдә бирү дә беркатлылык булыр иде. Дөрес, хәзер бу юнәлештә эш башланды. Әнә музыка мәктәбе ансамбле әгъзалары өчен концерт костюмнарына заказлар бирдек. Тик бюджет средстволарына гына яшәү бик тыйнаклык сорый шул. Химаячеләр, сәнгатькә гашыйк җитәкчеләргә үз игелекләрен күрсәтергә менә кайда җәй бар!

**- Әмма бу гына инициатива - ниятләрегезгә киртә куя алмыйдыр.**

- Юк, әлбәттә. Мәдәният бүлегендә бүген әллә никадәр ниятләр белән яшиләр. Алар арасында халык талантларын ачарга булышачак «Уйнагыз, гармуннар!» конкурсы, иҗат отчетлары, үзешчән спектакльләр смотр - конкурслары да бар. Авыл эшләре кампанияләре чорына элеккечә агитбригадалар чыгышларын да яңартырга уйлыйбыз, район мәдәният йортында аларның смотр конкурсын үткәрергә җыенабыз.

Шунысын ассызыклыйсым килә: күпмилләтле районда һәр халык мәдәниятына тигез караш, аларның үсешенә тигез шартлар сакланачак. Әлбәттә, мәдәният хезмәткәрләренә таләп тә үсәчәк. Авылларда үзешчән театр коллективларын торгызу, мәдәният ветераннарын, яшь талантларны сәхнәгә күтәрү, халыкка рухи азык бирү - аларның төп бурычы менә шулар, һәм алар шуңа хезмәт итәргә дә тиешләр. Халык исә аз гына үзгәрешне, игелекле омтылышны да дөрес аңлый, дөрес бәяли. Пыскып барган мәдәният учакларын тергезергә алынган һәркемгә алар зур рәхмәтле булырлар, кулларыннан килгән ярдәмне кызганмаслар, дип уйлыйм, ә район хакимияте исә таләп белән бергә булышлык та күрсәтергә һәрчак әзер.

**Әңгәмәдәш - С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

# Изге Корбан гаете узды

## КҮРЕШЕРГӘ ВАКЫТ ТАПТЫ

Корбан гаете көнне мәчетебезгә район хакимияте башлыгы Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин килеп кергәч, бермәл аптырап киттек. Хакимебез шулай иртәнге 4тән - 5тән торып район басуларын әйләнә, кырларның язгы кыр эшләренә өлгерү дәрәҗәсен, хуҗалыкларның аңа әзерлеген үзе карап йөри икән. Безнең басуларда булганнан соң, мәчетебезгә кереп, мөселманнарны олы бәйрәм белән котлап чыгарга да ниятләгән. Фатих Сәүбәнович мәчеткә җыелган халыкка район тормышы, анда көтелгән үзгәрешләр турында сөйләде, киләчәккә планнары белән уртаклашты. Картларның аның белән очрашудан бик күңелләре булды. Авылыбыз мулласы Хасибулла ага Мотыйгуллин авыл халкы исеменнән район мәнфәгатьләрен хәл итүгә ике куллап керешкән, зур планнар белән яшәгән, шул ук вакытта авыл халкы белән очрашып, җылы сүз белән алар хәлен дә белешергә вакыт тапкан өчен Фатих Сәүбәновичка рәхмәт белдерде, йөргән юлларында иминлек, сәламәтлек, уңышлар теләде.

**И.ШӘЙХИЕВ.**
**Зирекле авылы.**





**Гает намазларына халык күп йөри хәзер. Фотохәбәрчебез Н.АЗИЗОВ бу рәсемнәрне Норлаттагы мәчетләрдә төшереп алды. Уртада - тимер юл ягы мәчетендә Корбан гаете намаз вакыты, уңда - имам - хатыйб Зәкиулла хаҗи хәзрәт Әхмәтшин.**

## Мәгариф

# Тәҗрибә уртаклашабыз

Бүген мәктәп аерым игътибар үзәгендә. Илебезгә инициативалы, уйлап эш итүче, тормышка һәм хезмәткә әзер кешеләр кирәк - мәктәп шундый укучылар чыгарырга тиеш. Моның өчен төп җаваплылык укытучылар җилкәсенә төшә. Һәм яшь буынны тәрбияләү, аларга белем бирүдә башлангыч мәктәпнең иң мөһим чылбыр булып торуын исбатлау да кирәкмидер, мөгаен. Ул шәхес формалаштыруга, аның киләчәк үсешенә юнәлеш бирә. Шуңа аңардан сорау да зур, таләпләр дә көчле. Иң элек, педагогик осталыкны күтәрү өлкәсендә. Укытучыларның методик берләшмәләре дә бу юнәлештә зур ярдәм күрсәтергә чакырылганнар. Менә инде 7 еллап Андреевка урта мәктәбе башлангыч классларукытучыларының методик берләшмәләре үзәге булып тора. Безнең куста 4 урта мәктәп керә: Андреевка, Богдашкино, Иске Чаллы һәм Түбән Чаллы. Ел саен әлеге мәктәпләр укытучылары ачык дәресләр һәм класстан тыш чаралар үткәреп, аларны анализлыйлар, тәҗрибә уртаклашалар, укучылар практикумнары һәм концертлары оештыралар.

Безнең арада М.П.Алексеева (Богдашкино) һәм Л.А.Герасимова (Иске Чаллы) кебек тәҗрибәле укытучы - методистлар бар. Алар бай иҗат лабораторияләре булдыралар, дәресләре исә югары фәнни - теоретик дәрәҗәдә үтә.

В.И.Итрина (Түбән Чаллы), Н.П.Онгина (Богдашкино), В.А.Шартынова (Иске Чаллы), Л.Н.Белогубова, Е.М.Васильева (Түбән Чаллы) да дәресләрен методик яктан кызыклы, тирән эчтәлекле итеп төзиләр.

Әле күптән түгел генә яшь укытучы һәм педагогик осталык төшенчәләрен янәшә куюга күнегелмәгән иде. Шулай булса да бездә яшь педагоглар арасында иҗади шәхесләр аз түгел. М.В.Герасимова (Түбән Чаллы), Т.А.Борисова (Иске Чаллы), В.И.Иванова (Андреевка), Е.Г.Леукова (Иске Чаллы), М.А.Совкова (Богдашкино) нәкъ менә шундыйлар. Хәтта өлкәнрәк хезмәттәшләре дә аларның тәҗрибәләрен өйрәнәләр бүген.

Күптән түгел Андреевка урта мәктәбендә башлангыч классларукытучыларының йомгаклау киңәшмәсе булды. Ф.Ю.Грачева, В.А.Абрамова, В.И.Иванова биргән ачык дәресләр хезмәттәшләре тарафыннан киң яклау тапты анда. Шунда ук укытучыларның методик берләшмәсе тулаем бер елга йомгак ясады, киләчәккә бурычлар билгеләде. Безнең укытучыларның үз эшләренә һәм методик берләшмә утырышларында катнашуга намуслы карауларын билгелисе һәм хезмәттәшләребезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, түземлек, күр кәеф, иҗади уңышлар телисе килә.

**В.АБРАМОВА,**
**Андреевка кустының башлангыч классларметодик берләшмәсе җитәкчесе.**

